КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 ноябрь г.Казань № 1011

Татарстан Республикасы Министр-
лар Кабинетының кайбер карарла-
рына үзгәрешләр кертү турында

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 1999 ел, 10 декабрь, 813 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 626 нчы; 2008 ел, 4 август, 551 нче; 2010 ел, 14 декабрь, 1055 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3 нче пункттагы «16» саннарын «8» санына алыштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы; 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2016 ел, 19 декабрь, 951 нче; 2018 ел, 4 декабрь, 1082 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, II бүлекнең егерме икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы»;».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карарына (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 август, 610 нчы; 2015 ел, 5 ноябрь, 837 нче; 2015 ел, 5 декабрь, 921 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 673 нче; 2017 ел, 21 февраль, 104 нче; 2017 ел, 24 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 431 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1051 нче; 2018 ел, 3 октябрь, 899 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1325 нче; 2019 ел, 6 июнь, 473 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 – 2022 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасының II бүлегендәге беренче абзацында «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законында» сүзләрен «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законында» сүзләренә алыштырырга;

«2014 – 2022 елларга тармакның дәүләт идарәсе системасын үстерү» ярдәмче программасының I бүлегендәге унсигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы»;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасының мәдәни мирасын саклау стратегиясен раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1116 нчы карары белән расланган 2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасының мәдәни мирасын саклау стратегиясенә, V бүлекнең унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы»;».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторлары) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлектә:

4.25 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.26 нчы пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.27 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.41 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.42 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.47 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)»;

4.48 нче пунктның 18 графасындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (3, 4, 8 статьялар)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин